Бүгенге санда:



Социаль пакет: уйларга вакыт – 1 октябрьгә кадәр. 2 бит

1931 елның 9 июленнән бирле чыга

# Дуслык

Дружба

Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы

Чәршәмбе 19 август 2015 ел

№ 60 (10589)

20 августка һава торышы: болытлы һава, урыны белән яңгыр, җил төньяктан, 3-4 м/с; температура көндез +16°С, төнлә +12°С

ХӘБӘРЛӘРЕГЕЗНЕ КӨТӘБЕЗ

Телефоннар: 2-36-13, 2-36-20.

*Абзац-информ*

### ЯҢА ПОРТФЕЛЬЛЕ БУЛДЫЛАР

Күпбалалы, аз керемле гаиләләрдән шәһәр мәктәпләрендә укучы тагы 11 балага "Мәктәпкә җыенырга булыш" республика акциясе кысаларында мәктәп кирәк-яраклары тутырылган букчалар тапшырылды. Әлеге чара узган җомга көнне Халыклар Дуслыгы йортында үтте. Иганәчеләр – шәһәрнең оешма-предприятиеләре иде.

### УРАК ТА БАРА, АЗЫК ТА ӘЗЕРЛИЛӘР

Район хуҗалыкларында кичәге көнгә барлык мәйданнарның 70 процентында урып-җыю эшләре тәгәлләнгән, 58 мең тоннадан артыграк иген суктырылган, бер гектарга уртача уңыш 20,9 центнер тәшкил итә. Берүк вакытта азык әзерләү дәвам итә, бер баш шартлы терлеккә 18,7 центнер берәмлек азык әзерләнгән.

### АЙЛЫК АЛДЫННАН СӨЙЛӘШҮ ҮТТЕ

Кичә, 18 августта районның террорчылыкка каршы комиссиясе каршындагы эшче төркем утырышы үтте. Анда "Экстремизмга – юк!" террорчылыкка каршы айлыгы алдыннан комиссиянең чаралар планы турында фикер алышынды. Әлеге айлык Татарстанда 1-30 сентябрьдә узачак.

### КҮКРӘК БИЛГЕСЕ ТАПШЫРЫЛДЫ

Пенсия фонды системасында намуслы хезмәте өчен РФ Пенсия фондының Нурлат идарәсе начальнигы Рушания Мобин кызы Шакировага "РФ Пенсия фонды отличнигы" күкрәк билгесе тапшырылды.

### "ДУСЛЫК" ӨЧЕН ТАВЫШ БИРЕГЕЗ

Район газетасы "Татмедиа" АҖнең "Легендар брендлар" конкурсында катнаша. Безнең сайтта газета өчен тавыш бирегез. Бу бик ансат: газетаның nurlat-tat.ru сайтына кереп, уң яктагы өске почмакта "Туган газетагыз өчен тавыш бирегез" баннерына басасы. Аннан соң сул як почмакта тавыш бирә аласыз.

# Тирән сөрсәң – отарсың




"НУРЛАТ СӨТЕ" ХУҖАЛЫГЫ МЕХАНИЗАТОРЫ ВЛАДИМИР ВАСИЛЬЕВ БУ КӨННӘРДӘ КӨЗГЕ ЧӘЧҮДӘ МӘШГУЛЬ.

**Басуларда быелгы уңыш өчен кызу көрәш барган көннәрдә район хуҗалыклары тагы бер мөһим кампания – көзге чәчүгә керештеләр.**

"Нурлат сөте" җәмгыятендә быел уҗымнарны 3000 гектарлап мәйданда чәчеп калдырырга планлаштыралар. Уҗым культураларына шулай зур мәйдан бүлеп бирүләре исә юкка түгел, чөнки соңгы берничә корылыклы елда уңышны алар коткарып килде бит. Әлбәттә, аларны барлык технологияләрен истә тотып үстерүгә дә игътибар зур хуҗалыкта. Узган атна азагында биредә районда беренчеләрдән булып көзге чәчүгә төштеләр. Хуҗалык җитәкчесе Вәзир Сәгыйров әйтүенчә, көзге чәчү кампаниясен үткәрү өчен техникалары да, эшче көчләре дә җитәрлек, шул көннәрдә тагы ике чәчү агрегаты кайтарганнар әле. Яңа агрегатларының берсе белән узган атна азагында хуҗалык базасында көзге чәчү башлануга һәм урып-җыю барышына багышлап үткәрелгән район семинарында башка хуҗалык белгечләре дә таныша алдылар.

Семинарда исә чәчү алдыннан туфрак эшкәртүнең нечкәлекләренә аерым игътибар бирелде.

– Соңгы араларда хуҗалыкларда туфракның өске катламын эшкәртүгә күбрәк игътибар бирелә иде, - ди район авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең җитештерү-маркетинг бүлеге начальнигы Фаил Ивандеев. – Әмма болай эшләгәндә, аның өске катламы гына йомшара, ә аскы ягында үсемлек тамырларына дым үтүне кыенлаштыручы катлам барлыкка килә. Шуңа да 3-4 елга бер тапкыр булса да туфракны тирән сөрү кирәк. Гомумән, ел саен җирләрнең 30 процентлабы тирән эшкәртелергә тиеш.

Районның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе начальнигы Ислам Сафиуллин да тирән сөрү алымыннан файдаланырга киңәш итте.

– Күптән түгел республика буенча үткәрелгән зона киңәшмәләрендә дә әлеге агротехник чараның нәтиҗәлелегенә басым ясалды. Хуҗалыкларда моның өчен техника җитәрлек, киңәшләрне истә тотып эшләргә генә кирәк, - диде ул.

Хуҗалыкларда әлеге киңәш-тәкъдимнәрне инде гамәлдә куллана да башладылар. Бу атна башына тирән сөрү 6500ләп гектарда башкарылган. "Сөләйманов Ә.И", "Южная", "Нурлат сөте" һәм "Агромир" хуҗалыкларында аеруча актив эшлиләр.

Лилия **МӨБАРӘКШИНА**

**МӘГЪЛҮМАТ**

**Быел район буенча уҗым культураларын 19390 гектарда чәчү планлаштырыла. Чәчүне 5 сентябрьгә кадәр тәгәлләү бурыч итеп куела.**

АКТУАЛЬ

# Сораулар җавапсыз калмады

**Узган атнада нурлатлылар монополиягә каршы федераль службаның ТР буенча идарәсе белгеченә турыдан-туры сорау юллый алдылар**

13 августта районда эш визиты белән монополиягә каршы федераль службаның ТР буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары Игорь Павлов булып китте. Игорь Николаевич районның күпфункцияле үзәгендә гражданнарны кабул итте, монополиягә каршы службага кагылышлы сорауларга җавап бирде.

– Безнең идарә елына бер тапкыр республика районнарында планлы рәвештә гражданнар кабул итүне оештыра. Үзебезнең служба белән таныштырабыз. Максатыбыз – эшмәкәрләр, бизнес берләшмәләре һәм халык, районның муниципаль служба вәкилләре белән очрашу, аралашу. Безнең яктан Нурлат районына бернинди дәгъвалар юк. Сездә барлык мәсьәләләр дә көйле хәл ителә бара. Моны бүгенге кабул итү дә күрсәтте, – диде ул.

Эш визиты барышында Игорь Павлов районның муниципаль служба вәкилләре белән шәһәр Мәдәният сараенда очрашты. Муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләре товарлар белән тәэмин итүгә заказлар урнаштыру, дәүләти һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен хезмәтләр күрсәтү буенча сорауларга җаваплар алдылар. Очрашу барышында эшмәкәрләргә консультацияләр дә бирелде.

Зилия **ӘКСАНОВА**

БУРЫЧЛАР

# Әҗәтләр конфискациягә китерә



Автор фотосы

КОНФИСКАЦИЯЛӘНГӘН ТЕЛЕВИЗОР ҺӘМ КОМПЬЮТЕРНЫ САТКАН АКЧАЛАР БУРЫЧНЫҢ БЕР ӨЛЕШЕН КАПЛАУГА ТОТЫЛАЧАК

**Торак-коммуналь хезмәтләр өчен бурычлары булганнарга карата кырыс чаралар күрелә башлады.**

Узган атнаның пәнҗешәмбесендә Бердәм исәп-хисап үзәге, суд приставлары службасы, "Яшьлек" ТСЖсы вәкилләре, полиция участок уполномоченные Яшьлек микрорайонына чираттагы рейдка чыктылар. Биредә исә бурычлар аз түгел – 2799 мең сум. Мисал өчен, Совет ур., 195тәге бер фатирдагы бурыч 229 мең сумнан артыграк, тагы икесендә 182 һәм 149 мең сум, 189нчы йорттагы иң зур әҗәт 134 мең сум, Совет ур., 187дә – 69, Самаренкин ур., 18дә 46 мең сум... Дружба ур., 62нче йорттагы бер фатирның бурычы 233 мең сумнан артып китә. Алар хосусыйлаштырылмаган фатирда яшиләр.

– Фатир аларның милке түгел, шуңа да бер кешегә 6 квадрат метр тору урыны бирел, аларны фатирдан чыгару да мөмкин, – ди "ЕРЦ-Нурлат"ның ТКХ өчен бурычларны түләттерү буенча белгече Венера Мингалиева.

Дөрес, әлегә берәүне дә фатирыннан чыгармадылар, ә менә кайбер әҗәтлеләргә милекләре белән хушлашырга туры килде. Дружба ур., 78дә 2 бүлмәле бер фатирның хуҗалары 60 мең сумнан артык әҗәтле. Суд приставларына ишек ачылганчы, аны шактый гына дебердәтергә туры килде. Яшь гаилә башлыгы әле генә эшкә урнашкан икән, "шабашкага йөриячәкмен", диде ул үзе. Суд приставлары милекне язып барлый башлагач, хуҗабикәдә сорау туды – бу законлымы соң? Ә гаилә Бердәм исәп-хисап үзәгенең бурычларны түләтү өчен аларны судка бирәчәге турындагы хәбәрне алган. Әгәр әҗәтлеләр ЕРЦга килеп бурычларын түләгән булсалар, бу очракта башкарма кәгазь дә тутырылмаячак иде.

– Милек башкарма кәгазь булганда конфискацияләнә, арест шуның нигезендә салына да, – диде Венера Мингалиева. – Арест салынган милек бурычны түләү өчен реализациягә алына. Милекчеләр аларны үзләре дә сатып ала ала, әмма бурычларын түләмәсәләр, милек кабат конфискацияләнергә мөмкин.

Ресурс белән тәэмин итүче предприятиеләргә бурыч иң элек халыкка күрсәтелүче хезмәтләрнең сыйфатына кире йогынты ясый. Әгәр дә безгә нидер ошамый икән, без тиз арада телефон номерларын табып, шалтыратып зарлана башлыйбыз. Ә бит гаепләләр яныәшдә, бер үк йортта, подъездда гына яшиләр икән. Намуслы түләүчеләр акчасына ремонтланып торучы электр, су, җылылыктан файдаланалар. Ниһаять, катгый чаралар вакыты җитте. Һәркем үз счетлары буенча түләргә тиеш, ахыр чиктә конфискацияләнгән милек юлы белән булса да.

**Сирень СӘМӘРХАНОВА**

ШӘҺӘР



Автор фотосы

# Тагы бер парковка

**Шәһәрнең 9нчы мәктәбе янында автостоянка төзү башланды.**

Самаренкин урамы буйлап узучы әйләнеч юл – шәһәрдәге иң җанлы урындыр, мөгаен. Биредә күпфатирлы йортлардан тыш, балалар бакчасы, мәктәп тә бар. Шуңа да еш кына әлеге мәгариф учреждениеләре тирәсенә куелган машиналарны күрергә була, алар транспорт хәрәкәтенә комачаулый. Автостоянка юллардагы киеренкелекне киметәчәк, әлбәттә.

Эшләр дүшәмбе көнне башланды. 10 "КамАЗ", автоүзбушаткычлар, грейдер, төягеч, каток – барлык әлеге техника туфрак кабул итүдә, юл нигезен катламлап планлаштыру һәм тыгызлауда мәшгуль иде.

– Юл ком, вак таш һәм ике катлы асфальт-бетон өслектән торачак, – диде НУАДның юл участогы мастеры Нәфис Гыймалетдинов. – Автостоянканың мәйданы 515 квадрат метрлап булачак.

Бу участокта эшләр август азагына тәгалләнәчәк. Моннан тыш, НУАД юлчылары һәр 3-4 көн саен башка объектларын – йорт яны территорияләрен тапшырып торалар. Шәһәр башкарма комитетында әйтүләренчә, быел мондый эшләр 16 ишегалдында башкарылачак икән. Дружба урамының 70, 74, 76, 78нче йортлары ишегаллары асфальтланган инде. Мондый эшләр башкарылачак ишегаллары исемлегенә шәһәрнең төрле микрорайоннарындагы ишегаллары кергән: үзәктә дә, шикәрчеләр, тимер юлчылар бистәләрендә дә бар алар. Мисал өчен, дүшәмбе көнне юлчылар Гагарин ур., 1, 2, 4, 6нчы һәм Козлов ур., 4, 12, 14нче йортларның ишегалларында төп нигезне әзерләүгә керештеләр. Юл участогы мастеры Ленар Садыйков әйтүенчә, бар җирдә дә ике катлы асфальт-бетон түшәү планлаштырылган.

**Сирень СӘМӘРХАНОВА**

КЫСКАЧА

## ЭШЛЕКЛЕ ХАНЫМНАР ФОРУМЫ

**Дүшәмбе көнне районның 5 хатын-кызы "Казан" халыкара ат спорты комплексында узган III эшлекле хатын-кызлар форумында катнашып кайтты.**

Егоркино авыл җирлеге башлыгы Валентина Яковлева, Сукырлар җәмгыятенең җирле оешмасы рәисе Зинаида Богданова, шәхси эшмәкәр Ольга Мякишева, "Татарстан хатын-кызлары" оешмасының район бүлеге рәисе Фәридә Сәгыйрова, опека һәм попечительлек бүлеге начальнигы Ирина Савинова "Хатын-кызның активлыгы һәм аның республиканың икътисади һәм социаль-мәдәни үсешендәге роле" дигән темага сөйләшүдә катнаштылар Моннан тыш, районның эшлекле гүзәл затлары "Татарстан хатын-кызлары" оешмасы кубогына узган хәйрия ат чабышларын карагannар, эшләпәләр парадында катнашканнар.

**Зилия ӘКСАНОВА**


ДОСТАВКА ПЕРЕГНОЙ, ЧЕРНОЗЕМ, ГРУНТ, ПЕСОК, ПГС, И ДЕФЕКАТ
8-937-280-94-84.

**«УДАЧА»**
Отдых на Черном море - сентябрь (Сочинский район). Выезд на поезде, трехразовое питание. Цены смешные. Т. 8-927-417-17-10.

*Только с 22 по 25 августа* в школе №2 (г.Нурлат, ул. Школьная, 9) пройдет

**ЯРМАРКА ШКОЛЬНОЙ ОДЕЖДЫ**
от Ульяновской фабрики «ЭЛЕГАНТ» по ценам 2014 года.
22 августа - с 12.00 до 19.00
23 августа - с 8.00 до 19.00
24 августа - с 8.00 до 19.00
25 августа - с 8.00 до 15.00

**В КОНСУЛЬТАТИВНО-ДИАГНОСТИЧЕСКОМ ЦЕНТРЕ «САУЛЫК», Г. НУРЛАТ, УЛ. ЖЕМЧУЖНАЯ, 25, ВЕДУТ ПРИЕМ СПЕЦИАЛИСТЫ ИЗ Г. КАЗАНИ ПО СЛЕДУЮЩИМ НАПРАВЛЕНИЯМ:**

22 августа 2015 года
1. Взрослая, подростковая гинекология.
2. Педиатрия-кардиология.
3. Терапия, кардиология, ревматология.
4. Неврология.
5. Сосудистия хирургия.
6. Врачи проведут на высокотехнологичном оборудовании исследования сердца, эхокардиоскопию с ЦДК (цветное допплеровское картирование), исследования сосудов головного мозга, верхних и нижних конечностей.

23 августа 2015 года
1. Отоларингология.
2. Эндокринология.
3. Аллергология. Иммунология. Решение проблем бронхиальной астмы, аллергических дерматитов, кожных заболеваний.
4. Пульмонология.
5. Гинекология, репродуктология. Решение проблем при бесплодии. Ведение беременности.
6. Диетология.
7. Врачи проведут исследования органов малого таза, плода на 1,2 и 3 триместрах.

29 августа 2015 года
1. Гастроэнтерология.
2. Онкогинекология.
3. Терапия, кардиология, ревматология.
4. Врачи проведут на высокотехнологичном оборудовании исследования сердца, эхокардиоскопию с ЦДК (цветное допплеровское картирование).

КДЦ предлагает услуги по ДМС через Нурлатский филиал СК «Чулпан».
Результаты обследования принимаются в БМСЭ.
Справки и предварительная запись по т.: 2-43-03, 8-927-037-40-01.

ООО «Услуга» КДЦ «Саулык». Лиц. ЛО-16-01-001191 от 30.09.2010г. ОГРН 1021605358103.

**Имеются противопоказания. Необходима консультация специалиста**

Реклама

*Продается магазин* **«КАЛЕЙДОСКОП»** на продуктовом рынке (36 кв.м, помещение и земля в собственности, можно как готовый бизнес «Колготки»).
**РАСПРОДАЖА с 19.08.15 по 25.08.15 подробности по т. 8-927-424-85-61.**
Организатор ИП Садыкова З.Ф.

*Продается магазин* **«СПОРТТОВРЫ И ИГРУШКИ»** на продуктовом рынке (50 кв.м, помещение и земля в собственности), готовый бизнес.
**РАСПРОДАЖА с 19.08.15 по 25.08.15 подробности по т. 8-927-424-85-61.**
Организатор ИП Садыкова З.Ф.


**ВНИМАНИЕ, РОЗЫСК!**



Отделом МВД России по Нурлатскому району разыскивается как без вести пропавший Ткаченко Николай Григорьевич, 27.04.1939 г.р. Страдает потерей памяти, после инсульта.

Приметы: рост средний 160-170 см, 76 лет, худощавого телосложения, глаза голубые, голос глухой, волосы седые, на подбородке шрамы, речь невнятная, сутулится.

Был одет: куртка серая, короткая, трико синее, лампасы белые, на ногах сандалии черного цвета.

Всем, кто располагает какой-либо информацией просим сообщить по телефонам: **8(84345) 2-11-25, 89270361901, 02.**

# НОРКА 69 000 руб.



РАССРОЧКА*

БЕЗ ПЕРЕПЛАТЫ до 2-х лет

**21 августа**

в здании типографии

(ул. К.Маркса, 19, 2 этаж)

МОРОЗКО

Белка

*Рассрочку предоставляет ИП Плотников Д.И. Реклама

**ООО «МИР КРОВЛИ»**

**реализует**

ПРОФНАСТИЛ С9, С20, С21, НС44, Н60, Н75 (оцинкованный и окрашенный), длина до 12 метров, металлочерепицу, металлосайдинг, металлоштакетник, профильную трубу, гладкий лист, доборные элементы. Утеплитель. Пароизоляция.

Поликарбонат. Теплицы.

Доставка по городу бесплатно.

Гарантия на всю продукцию.

**Т.: 8-927-826-53-32, 8-937-273-87-15, 8(84235) 2-75-35, 8(84235) 2-75-25.**

**E-mail: mir-krovli73@bk.ru**

**ВНИМАНИЕ!!!**

**Только с 1 по 31 августа 2015 г.**

Компания "Оконные системы"




**Окно 1300х1400**

Подоконник 300 мм

Отлив 150мм

Монтаж с демонтажем

При заказе более 2-х окон:

**ПОДАРОК до 1000р с окна***

| Rehau | KBE | Montblanc | Exprof |
| --- | --- | --- | --- |
| 7700 руб | 7200 руб | 6500 руб | **6000** руб |

**т. 8-927-742-66-67, 8-908-383-89-98**

*Подробности по указанным телефонам. Организатор: ООО "СВК". Реклама

**Требуются охранники с лицензией и без лицензии** для работы на промышленных объектах в городах РФ.

*График работы - две недели через две.*

Официальное трудоустройство. Бесплатное питание, проживание, доставка.

**З/п 850-900 руб. сутки для охранников без лицензии, 1000-1150руб. сутки - с лицензией.**

**Т. 8 937 986 76 81.**

# СКОРО В ШКОЛУ!

**ТРАДИЦИОННОЕ СНИЖЕНИЕ ЦЕН НА КАНЦЕЛЯРСКИЕ ТОВАРЫ!**

**тетрадь - 1 руб.**



**ручка шариковая -1,5 руб.**

ЦИФРОПАРК

**г. Нурлат, ул. К.Маркса, д.10**
**тел.: (84345) 2-91-33, 2-91-44**

Акция действует с 01.08.15 г. по 31.08.15 г. Подробности у продавцов-консультантов. Организатор: ООО "Элис". Реклама

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Фома авылында туып, Нурлатта яшәүче кодагыебыз **Рәйсә Низамованы** гомер бәйрәме – 55 яшьлек юбилее белән ихлас күңелдән котлыйбыз. Аңа исәнлекле озын гомер, күңел тынычлыгы телибез.

Кодагый! Балаларыңның һәм оныкларыңның игелеген күреп, кода белән пар канат булып, мул тормышта яшәвегезне, бәхетле гомер кичерүегезне телибез.

**Көрнәле Әмзәдән кодаң Рамил, кодагыең Фәнилә һәм балалар.**

## НЕДВИЖИМОСТЬ

*дом, ул. Дубравная, 44. Т. 8-927-248-87-85.

*дом в с. Егоркино. Т. 8-937-441-07-56.

*3-комнатная квартира, мкр. Яшлек, 3 этаж, ремонт не требуется. Т. 8-927-439-69-54.

*дом. Т. 8-927-462-17-01.

*кирпичный дом, срочно, дешево. Т. 8-927-475-32-03.

*1-комнатная квартира, ул. Нефтяников, 9, 780 тыс.руб., торг. Т. 8-927-400-24-23.

*Участок, Советская, 63. Т.8-937-280-17-90.

*дом, д. Средняя Камышла. Т. 8-960-809-38-31.

*1-комнатная квартира, 39 кв.м, с/з. Т. 8-927-468-38-91.

*квартира (ул. Промышленная), сад, баня, гараж. Т.: 8-9376-160-170, 8-9274-34-34-43.

*3-комнатная квартира, ул. Кариева. Т. 8-927-457-40-44.

*2-комнатная квартира, центр. Т. 8-917-939-99-36.

*дом деревянный, самовывоз. Т. 8-927-673-44-49.

*дом, ж/д. Т. 8-927-431-48-09.

*недостроенный дом, участок 25 соток, с. Фомкино, 250000 руб., торг. Т. 8-927-708-20-54.

*дом, ул. Ленинградская, 35, участок 10 соток, цена 3500 тыс.руб. Т. 8-929-727-45-34.

*дом или обменивается на 2-комнатную квартиру. Т. 2-19-57.

*2-комнатная квартира, ул. Тельмана, 7, 50 кв.м. Т. 8-927-403-28-00.

*2 больших гаража, крайние, рядом, можно под СТО, мкр. Яшлек, около рабочего автовокзала. Т.: 8-927-676-51-45, 8-927-418-04-81, 2-80-31 (дом.).

*2-комнатная квартира, ул. Ст.Разина. Т. 8-927-243-65-08.

*дом 116,4 кв.м. с земельным участком, ул Михеева, 21-1. Цена 2600000. Т. 8-927-249-25-35.

***1-комнатная кваартира** , ул. Ленина,45. ,цена 550000, **1-комнатная квартира**, ул. Куйбышева, цена 830000, **недострой** (сосна) ул. Центральная, цена 550000. Т. 8-937-600-47-73 Алсу.

## АВТОТРАНСПОРТ

*трактор ЮМЗ, прицеп, культиватор. Т. 8-960-809-38-31.

*«Шевроле Лачетти», седан, 2008 г/в, серебристый. Т. 8-937-592-45-14.

*«ВАЗ-2110», 2001 г/в. Т. 8-927-031-69-40.

*«ВАЗ-21144», 2007 г/в, пробег 143000, цвет «кварц». Т. 8-917-277-02-58.

## ДРУГОЕ

*утки, гуси, молодки, бройлеры. Доставка. Т.: 8-937-286-57-23, 8-937-621-81-57.

*песок, ПГС, бут, щебень, цемент, керамзит. Т. 8-927-401-51-91.

*бут, песок, ПГС, цемент, щебень, керамзит. Т. 8-927-247-94-76.

*ПГС, песок, перегной, глина от 3 т. Т. 8-927-424-02-83.

*бычки, куры-молодки, бройлеры, несушки, утки, гуси. Т.: 8-927-483-06-10, 8-917-293-27-47.

*бычки, молодняк, от 2 до 5 м. Т. 8-927-870-58-98.

*ПГС, песок, бут. Т. 8-927-402-13-40.

*куры, утки, муларды. Т.: 4-35-11, 8-927-422-92-58.

*бычки (молодняк). Т. 8-927-870-49-62.

*бычки. Т. 8-927-987-87-63.

*перегной, бут, грунтощебень. Т. 8-927-463-63-17.

*мягкая мебель, спальный гарнитур. Т. 8-927-406-50-51.

*козье молоко. Т. 8-927-443-76-66.

*ПГС, песок, щебень, дрова, перегной, сруб для бани, новый. Т. 8-927-413-05-92.

*ПГС, бут, песок. Т. 8-987-283-18-34.

*ПГС, бут, песок. Т. 8-927-675-54-96.

*сруб 5х3х2,20, 5-стенка. Срубим срубы под ваш размер. Т. 8-937-283-19-51.

*кобыла орловской породы, возраст 3 года. Т. 8-927-76-06-023.

*дрова. Т. 8-927-414-61-34.

*дрова, ПГС, песок. Т. 8-937-617-11-21.

*песок, ПГС от 3 тонн. Т. 8-927-244-84-71.

*ПГС, песок, бут. Т. 8-927-247-27-37.

*дрова. Т. 8-937-003-27-27.

*тележка от «УАЗ». Т. 8-927-454-11-85.

*коза дойная, безрогая, черно-белой масти. Т. 8-927-443-68-04.

*сруб 3х3. Т. 8-929-729-45-36.

*кобыла, 2 года. Т. 8-987-266-23-51.

*шифер, б/у (50 руб.), доски, б/у (50 руб.). Т. 8-937-525-60-85.

*б/у телевизор, компьютерный стол, мягкий угол, прихожая, спальный гарнитур. Т. 8-927-458-64-54.

*газовая плита «Идель». Т. 8-927-429-07-83.

## РАЗНОЕ

*Йомшак җиһаз тарттыру, ремонтлау. Т. 8-937-570-60-21.

*Йөк күчерү, «ГАЗель». Т. 8-937-570-60-21.

*тамада. Т. 8-960-088-23-94.

*копаем, заливаем фундамент, копаем траншеи и канализации, чистим колодцы. Качественно, вручную. Т.: 8-986-711-25-32, 8-929-723-88-60 (Олег).

*такси Нурлат-Самара, ежедневно. Т. 8-927-673-79-46.

*ремонт холодильников на дому. Т. 8-927-419-56-48.

*услуги погрузчика. Т. 8-927-402-13-40.

*кровля, штукатурка, вагонка, бетонные работы. Т. 8-917-865-30-35.

*ремонт холодильников. Т.: 2-71-69, 8-937-610-58-78.

*КРОВЛЯ И ВСЕ ВИДЫ СТРОИТЕЛЬНЫХ РАБОТ. БЫСТРО И КАЧЕСТВЕННО. Т. 8-927-422-26-33.

*кузовной ремонт. Т. 8-917-865-30-35.

*отопление, водопровод, теплый пол. Т. 8-927-412-22-41, Радик.

*персональная фотосъемка (никах, юбилеи и т.д.). Т. 8-927-401-12-63.

*ремонт стиральных машин. Т. 8-927-468-16-31.

*установка дверей, окон, откосов. Т.: 8-927-671-26-59, 8-987-189-59-02.

*маникюр, педикюр, депиляция. Т. 8-927-418-31-93.

*сантехника (вода, канализация, отопление). Т. 8-937-526-56-86.

*помощь компьютеру. Т. 8-909-308-22-56.

*бильярдный стол, емкость 20 кв.м. Т. 8-937-281-75-63.

*шпаклевка, поклейка обоев. Т. 8-929-726-83-76.

*уважаемые жители села Биляр-Озеро и гости! Приглашаем вас на праздник – День села, который состоится 22 августа 2015 года в 18.00.

## СДАЕТСЯ

*в парикмахерской сдаются в аренду рабочие места. Т. 8-937-287-68-88.

*2-комнатная квартира. Т.: 8-927-474-46-16, 8-927-248-02-05.

*комната, желательно женщине. Т. 8-929-726-83-76.

## ТРЕБУЕТСЯ

*парикмахер. Т. 8-937-287-68-88.

*слесари в СТО. Т. 8-927-442-66-89.

*слесарь в м-н «Автомасла», з/п высокая. Т. 8-927-442-63-62.

*главный бухгалтер в строительную организацию, водитель на а/м «ГАЗель». Т.: 8-937-772-26-30, 95-052.

*парикмахер. Т. 8-927-418-31-93.

*ухаживающий (ая) за женщиной с проживанием. Т. 8-927-440-14-10.

*рабочие строительных специальностей. Т. 8-927-400-84-34.

*ООО «РНК+» электрогазосварщики, монтажники наружных трубопроводов. Т. 8-917-298-41-35.

*в СТО мастер на ходовую, автоэлектрик. Т. 8-937-529-18-88.

*ООО «Нурлатское УТТ» на работу мотористы цементировочного агрегата, машинисты крана автомобильного с соответствующими квалификационными удостоверениями, водители с категориями «ВСДЕ» и ДОПОГ на перевозку опасного груза. Телефоны для справок: 90-154, 90-092.

*строительной организации бригада электриков и электромонтажников, оплата высокая. Т.: 2-28-78, 8-937-299-82-62, 8-917-935-05-76.

*электрик. Т. 8-917-398-26-41.

## КУПЛЮ

*»ВАЗ» переднеприводный, иномарки. ДОРОГО. Т. 8-927-456-00-07.

*КРС и шкуры КРС, дорого. Т. 8-927-443-05-43.

*баллоны кислородные и т.д. Т. 8-987-292-01-10.

*участок. Т. 8-927-413-86-26.

*КУПЛЮ АВТО. ДОРОГО. Т. 8-937-588-36-46.

*КРС, шкуры КРС. Т. 8-927-412-29-99.

*овечью шерсть. Т. 8-937-592-37-56.

*участок в мкр. для многодетных семей, недорого. Т. 8-917-905-90-76.

## СНИМУ

*1-комнатную квартиру в мкр. Яшлек. Т. 8-927-248-39-93.

*семья чистую 2-комнатнаю квартиру в районе школы №9. Т. 8-937-773-98-04.

*квартиру на длительный срок. Т. 8-987-125-13-01.

## ОБМЕН

*3-комнатная квартира, Наб.Челны (12 комплекс, 71 кв.м, 3600 тыс.) на 1-комнатную в Наб.Челнах или на 2-комнатную в Нурлате. Варианты. Обращаться: д. Русская Менча, 2-я Набережная, 21.

## ПОТЕРИ

*военный билет на имя Дмитрия Евгеньевича Клевлина прошу вернуть за вознаграждение. Т. 8-939-754-14-80.

*утерянный ПСМ ВЕ 347065 ст 08-05, выданный в 2008 г., считать недействительным.

**Гамәлгә куючы: "ТАТМЕДИА" АҖ** www.tatmedia.ru www.nurlat-tat.ru

"Дуслык" ("Дружба", "Туслах") газетасы
Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы

"Татмедиа" АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир С.Н. Хәйруллина
Тел.: 2-36-14

**Редакциянең адресы:**
423040, ТР, Нурлат шәһәре, К.Маркс ур., 19
**Электрон адрес:** e-mail: redak@list.ru
**Телефоннар**: 2-36-12 – җаваплы сәркатип, реклама бүлеге, факс
2-36-20 – рус бүлеге
2-36-13 - корреспондентлар
2-25-88 – бухгалтерия

**Нәшер итүче:**
"ТАТМЕДИА" АҖ 420097, Казан шәһәре, Академическая урамы, 2.

Газета элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәтнең Татарстан Республикасындагы (Татарстан) идарәсе тарафыннан 2013 елның 16 маенда теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы: ПИ № ТУ 16-01018
Бу сан "Татмедиа" АҖ филиалы "Идел – Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылды
Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2.
Басуга тапшыру вакыты:
график буенча – 14.30,
фактта – 14.30

татмедиа

Тираж - 1642

Авторлар фикере редакция фикере белән муафыйк булмаска да мөмкин.
Редакциянең рәсми оешмаларда яклаучы булып чыгарга мөмкинлеге юк.
**Кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.**
Реклама белдерүләренең төгәллеге өчен реклама бирүче үзе җаваплы.

Газета **чәршәмбе** һәм **җомга** чыга.
Заказ №5970
Язылу индексы – 16185
Бәясе ирекле.

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән әзерләнде.

12+

© Язмаларны күчереп бастыру редакциянең язмача рөхсәте белән генә мөмкин.

